**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
____16.05.2019_____

КАРАР
____ПР-110__

**“Актаныш муниципаль районы хуҗалыкларында җәмәгать туклануы иң яхшы оешмаларына (предприятиеләренә) конкурс үткәрү турында”**

Хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү, заманча мәгълүмати технологияләр мөмкинлекләрен куллану һәм җәмәгать туклануы оешмаларын (предприятиеләрен) кыр эшләре вакытында механизаторларга хезмәт күрсәтү системасын камилләштерүдә куллану, Актаныш муниципаль районы хуҗалыкларына җәмәгать туклануы предприятиеләре күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм конкурентлылыгын арттыру нигезендә кулланучылар өчен максималь уңайлыклар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Актаныш муниципаль районы хуҗалыкларында җәмәгать туклануы иң яхшы оешмаларына (предприятиеләренә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымта нигезендә, расларга.

2. 2 нче кушымта нигезендә Актаныш муниципаль районы хуҗалыкларының иң яхшы җәмәгать туклануы оешмаларына (предприятиеләренә) конкурс үткәрү буенча комиссия төзү.

3. Актаныш муниципаль районы хуҗалыкларының иң яхшы җәмәгать туклануы оешмалары (предприятиеләре) конкурсына 2019 елның 16 маеннан 1 июленә кадәр документлар кабул итүне игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Сираева Л. Р.га йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш. Бариев